РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОГРИШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ул.Молодежная, д.1, с.Старое Гришкино,
Менделеевский район, Республика
Татарстан, 423642

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 1 йорт,
Иске Гришкино авылы, Менделеевск
районы,
Татарстан Республикасы,423642

Тел. (факс): (85549) 3-51-18
e-mail: Sgr.Men@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 июль 2026 ел № 12

Менделеевск муниципаль районының
Иске Гришкино авыл җирлеге территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын
урнаштыру схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын кушымта нигезендә расларга.

2. Биш көн эчендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруның күрсәтелгән схемасын Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына тапшырырга.

3. Әлеге карарны җәмәгать урыннарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Иске Гришкино авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам

Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И.Алексеев

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль
районы Иске Гришкино авыл
җирлеге башкарма
комитетының 2026 елның 28
июлендәге 12 нче номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № | Стационар булмаган сәүдә объектларының урнашу урыны исеме | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектлары тибы (павильон, киоск, автомагазин, автолавка, тонар, | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының стационар булмаган сәүдә объектларыннан файдалануы | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Карманково авылы, Урман ур. № 15 йорт каршында | Сөт продуктлары, казылык эшләнмәләре, сырлар, кондитер эшләнмәләре, икмәк, яшелчә һәм җиләк-җимеш, кипкән җиләк-җимеш | Автолавка | әйе | Атна саен чәршәмбе көнне 13.00 сәг 15.00 сәг. кадәр |
| 2 | Иске Гришкино авылы , Елга аръягы ур. № 19 йорт янында | Балалар уенчыулары, кондитер эшләнмәләре, | Палатка | әйе | Ел әйләнәсе |